**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге
Ләке торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 21 ноябре № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыены нигезендә **Карар**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге территориясендә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хәрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1)Ләке торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Ләке торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, Тау башы урамындагы юлларга вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу,юлга салу һәм тарату);

3) Ләке торак пунктында җәйге чорда торак пункт территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу;

4) Ләке торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, таймерларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) Ләке торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял

итә торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (шартнамә буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы ____________ Ю.Г.Антонов